**СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Куркачи , ул. Клубная, 4

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы , Клуб урамы, 4

тел./факс 8(84365) 70-7-00, e-mail:Ikaz..Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 декабря 2018 ел** **№ 140**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 нче елның 15 нче октябрендәге 9 нчы номерлы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы,Иске-Казан авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Советы нигезендә

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Советы карарына 2015 нче елның 15 нче октябрендәге 9 нче номерлы (Совет карарын 2018 нче елнын 27 нче апрелендэ 105 нче номерлы, 2018 нче елнын 17 нче сентябрендәге 122 нче номерлы редакциясендә) «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктның 2 нче пунктчасындагы 2 нче абзацтагы сүзләреннән соң - фатирларда сүзләрне өстәргә; «, фатирлар өлешләре;»;

1.2. 2 нче пунктның 3 нче пунктчасындагы 2 нче абзацтагы сүзләреннән соң «,торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;»;

1.3. түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:

«3.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән ата-ананың берсенең (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) физик затлар мөлкәтенә салымны түләүдән азат итәргә, аның белән бергә 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк бала яши.

Салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган һәр төр салым салу объектына карата бирелә: салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган фатир (бүлмә) яисә торак йорт (торак йорт өлеше).

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы

территориясендә даими яшәүче (теркәлгән) салым түләүчеләргә бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турындагы гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы, Коркачык авылы, Клуб урамы, 4 нче йорты, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында, http://vysokaya-gora.tatarsta№ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2019 нчы елның 1 нче гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Советы рәисе,
Иске-Казан авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова